**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ СРЕДНЕДЕВЯТОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**УРТА ДЕВЯТОВО АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422614 с.Среднее Девятово
ул. Сергеева, д.9
тел: 8-(84378)-3-41-11
факс: 8-(84378)-3-41-11
Sdev.La@tatar.ru

422614 а.Урта Девятово
Сергеев урамы, 9 нчы йорт,
тел: 8-(84378)-3-41-11
факс: 8-(84378)-3-41-11
Sdev.La@tatar.ru

**2023 елның «27» августы** **27 номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2021 елның 19 октябрендәге 37 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Лаеш муниципаль районы Урта Девятово авыл җирлеге Советы «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән карар **кабул итте**:

1) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2021 елның 19 октябрендәге 37 номерлы карарына, кушымта нигезендә, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2) Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3) Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Урта Девятово**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы** **К.М.Ипатова**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы
Урта Девятово авыл җирлеге Советының 2023 елның 27 августы
27 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2021 елның 19 октябрендәге 37 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү

**1) 2.2 пунктындагы «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

"Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында»2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе) тарафыннан вәкаләтләнгән махсуслаштырылган оешмалар милкендәге җир кишәрлекләренә карата 0,001%;".

».